**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**СТОЛБИЩЕ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕНЕН**
**БАШКАРМА КАМИТЕТЫ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-12-91

---

**№4** **2019 елның 12 апреленнән**

**КАРАР**

**Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүнең административ регламентын раслау турында**

2010 елның 27 июленнән №210-ФЗ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябреннән №880 “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан тәкъдим ителүче дәүләт хезмәтләренең административ регламентларын эшләү һәм раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында"гы карарына, Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 13 ноябреннән №2027 “Лаеш муниципаль районы башкарма органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында”гы карарына ярашлы төстә **карар бирәм:**

1. Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүнең административ регламентын (Кушымта) расларга.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
3. Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 26августыннан №16 “Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүнең административ регламентын раслау турында”гы Карарын көчен югалткан дип табарга.
4. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне Столбище авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе В.В.Михеевка йөкләргә.

**ТР Лаеш муниципаль районы**
**Столбище авыл җирлеге**
**җитәкчесе** **В.В.Михеев**